# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# КЕЧЕ ШИЛНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГ»
# БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ

22.09.2016 № 258

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлегендә җирле референдум үткәрү инициативасы турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «җирле референдум турында»2004 елның 25 мартындагы 23 - ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20, 35 статьялары, Иштирәк авыл җирлеге Уставы нигезендә

**КАРАР БИРӘМ**

1. Кече Шилнә авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе белән берлектә Кече Шилнә авыл җирлегендә җирле референдум үткәрү турында инициативаны тәкъдим итәргә.

«2016 елда яшәү урыны буенча Кече Шилнә авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләрдән тыш, 200 (ике йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

а) Кече Шилнә авылы Ленин урамында җәяүлеләр тротуарын урнаштыру - сумма: 60 600 сум 00 тиен;

б) Кече Шилнә авылы Мәскәү урамында җәяүлеләр тротуарын урнаштыру, сумма: 46 000 сум 00 тиен;

в) юлны вак таш җәее ремонтлау. Ильбухтино авылы, Верхняя ур. - сумма: 29 000 сум 00 тиен;

г) Олы Шилнә авылы Титов урамында җәяүлеләр тротуарын урнаштыру: - сумма: 49 200 сум 00 тиен;

2) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктыртуны да кертеп):

а) Кече Шилнә авылы Мәскәү урамын яктырту приборларын сатып алу һәм урнаштыру - 47 000 сум 00 тиен;

б) Кече Шилнә авылы Даричев урамын яктырту приборларын ремонтлау һәм урнаштыру, сумма - 49 200 сум 00 тиен;

в) Ильбухтино авылы урамын яктырту приборларын сатып алу һәм урнаштыру-сумма: 33 800 сум 00 тиен.

3) җирлектә яшәүчеләрнең массакүләм ял итүе өчен шартлар тудыру һәм халык күпләп ял итә торган урыннарны төзекләндерүне оештыру:

а) Олы Шилнә авылы 70 микрорайонда балалар мәйданчыгын төзекләндерү - сумма: 50 000 сум 00 тиен;

б) Олы Шилнә авылы Казан урамында балалар мәйданчыгын сатып алу һәм урнаштыру - сумма: 72 000 сум 00 тиен;

в) Белоус авылы Лесная урамында балалар мәйданчыгын сатып алу һәм урнаштыру - сумма: 56 200 сум 00 тиен.

2. Әлеге карарны Тукай территориаль сайлау комиссиясенә җибәрергә.

3. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмати стендларында һәм Тукай муниципаль районы порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, салымнар, финанслар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Г.Н. Харитонов